# ЮККА ҮПКӘЛӘМӘ

*Венер Мухаммадиев шигыре һәм көе*

Күңелкәем канатланды
Сине тәү күргән чакта.
Хәзер яна йөрәккәем
Уйласам синең хакта

*Кушымта:*
Юкка үпкәләгән булып,
Ятларга китәсең бит.
Аны, мине, үзеңне дә
Бәхетсез итәсең бит.

Оныт, дисең, араларны
Ничек өзәем икән.
Аерылу газабына
Ничек түзәем икән.

*Кушымта.*

Хәтерләсәң яшьлегеңне
Күзләреңә яшь тулыр.
Эх, диеп бер үкенерсең,
Гомерләр үткән булыр.

*Кушымта:*
Юкка үпкәләгән булып,
Ятларга китәсең бит.
Аны, мине, үзеңне дә
Бәхетсез итәсең бит.